Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Сугышлы авыл җирлегенең
Юлтимер торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

а) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Юлтимер торак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан үлән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр ечен түләү, иске авария агачларын кисү (килешү буенча эшләрне түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

б) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:

- Юлтимир торак пункты юлларын кардан чистарту (Совет ур., Игтисамовлар ур.);

- Юлтимер торак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) юлдагы чокырларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 223 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 117.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 117 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге составына керүче Юлтимер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дерес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

а) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү елкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Юлтимер торак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан үлән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, иске авария агачларын кисү (килешү буенча эшләрне түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

б) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:

- Юлтимир торак пункты юлларын кардан чистарту (Совет ур., Игтисамовлар ур.);

- Юлтимерторак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) юлдагы чокырларны ремонтлау ямау сораулары буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Зыятдинова